ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.11.2025 с.Старое Дрожжаное №511

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү өчен Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 декабрендәге 1270 номерлы карарына таянып (15.11.2022 № 1214, 12.05.2025 № 314, 25.11.2025 № 979 редакциясендә), Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1 Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 28 августындагы 375 номерлы (02.02.2023 № 52 редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен стимуллаштыручы өстәмә түләү өчен Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Тәртиптә педагогик хезмәткәр-яшь белгеч дип төп һөнәри белем бирү программалары һәм (яки) һөнәри белем бирү программалары буенча укуын тәмамлаган, алынган квалификациясе нигезендә беренче тапкыр эшкә урнаша торган, шул исәптән төп һөнәри белем бирү программалары һәм (яисә) һөнәри белем бирү программалары буенча уку чорында алынган хезмәт стажы булган 35 яшькә кадәрге (кертеп) Россия Федерациясе гражданы таныла.»;

**5 нче пунктта** «2 510 сум» сүзләрен «10 000 сум» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Җитәкче

Р.И. Мөхәммәтҗанов